Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Ямбакты авыл җирлеге Советы

КАРАР РЕШЕНИЕ

№ 110-1 31.01.2024ел.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 24.10.2023 № 101-1 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге советы карары:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге советының «Җир салымы турында» 24.10.2023 № 101-1карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 1.2 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:
"авыл җирлеге башкарма комитетының даими (вакыты чикләнмәгән) файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата»;
- 3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге дүртенче абзац белән тулыландырырга:
"җирле үзидарә органнары, гомуми файдаланудагы территорияләр (парклар, скверлар, ял итү зоналары, урман утырту һ.б.) биләгән җир участокларына карата».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Ямбакты торак пунктларында, шулай ук ТР Спас муниципаль районының рәсми сайтында(http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru). урнаштыру юлы белән игълан ителергә тиеш

Ямбакты авыл җирлеге башлыгы: И.Э.Галэветдинов